

Музей – vткәннәргә сәяхәт. Музей – халык, милләт хәтере, ул халкыбызнын бай тарихы, мәдәнияте, гореф-гадәтләре, йолалары, шәхесләре белән таныштыра. Менә шундый музей Кадошкино районы Большие Поляныда яшәvче оештырган.
Без яшәгән донья искиткеч кин, гvзәл һәм гажәп. Арабызда соклангыч кешеләр дә кvп. Шуларнын берсе – Гульнара Хаким кызы Дербердеева. Ул vзенен оендә тарихи музей оештыра башлаган. Анда тормыш-конкvреш әйберләре, борынгы авыл жиһазлары, самоварлар, савыт-саба, иске акчалар... Һәр экспонат тәртип белән матур итеп урнаштырылган. Анда килеп керvгә vзенне башка атмосферага эләккән сыман тоясын. Саранск шәһәрендә яшәvче татар кешесе туган авылындагы нәсел (родовое гнездо) йортында музей оештыра. Барлык әйберләр Хамзя кызы Әйшә апай Долотказинага әтисе Хамзя бабай, бабайнын әти-әнисе куллары тигән, алар шулар белән кулланган жиһазлар кала. Болар барысы да тарихи әйберләр.       Лапаста (хужалар аны беседка кебек янарткannар) 100 якын экспонат бар. Алар арасында кvмер vтvкләре, берничә торле лампа, абажурлы лампочка, табагач, кисәv агачы –ниләр генә юк! Әти-әниләре, әби-бабайларынын конкvрештә кулланган әйберләрен кадерле ядкарь итеп саклый Гульнара Хаким кызы. Хәтта ой эче бvрәнәләре, андагы борынгы шкаф, козге, жиһазлар да кадерле урын алып интерьерны бизәп тора.



– Берсен дә чvпкә чыгарып атмадым. Мона минем кулым да бармас иде. Лапас алдына утырып, хатирәләрне искә тошерvгә ни житә! Үткәннәрне онытырга ярамый, – ди Гульнара Хаким кызы.
Барлык экспонатлар да иске абзарны (сарайны) жимереп янасын тозегәндә чыкканнар. Элеккеге конкvреш кирәк-яракларын, ягъни жир эшкәртә торган тимер сабан һәм тагы берникадәр әйберләр бу музейда vзләренен урыннарын алачаклар. Хужабикәнен кызыксынуын белгән туганнары, авыл кешеләре ойләрендә сакланган борынгы әйберләрне музейга алып киләләр. Мәсәлән, агач тарак...
Табигат



е белән тыйнак, татар хатын-кызына гына хас тәрбиялелеге кvренеп торган Хаким кызы Гульнара белән тынышырга вакыт житте. Ул белеме буенча педагог, Казан педагогия университетын тәмамлап, гомере буена Саранск шәһәрендә хормәтле балалар тәрбиячесе булып хезмәт итте. Хәзер лаеклы ялда. Тормыш иптәше Альберт Хасян улы белән жәйләрен туган авылларында vткәрәләр. Бакчалары - сокланып туймаслык. Ой

алды тирәләрендә дизайн белән урнаштырылган чәчәкләр, арба тәгәрмәчләре, аккошлары рәхәтлек бирә; кvнелгә нәфислек ости.
– Лапас алды – бик жайлы урын ул. Башта уйлар ботерелә башлады. Нигә әле керосин лампаларын, vзем чутлаган счетларны, самоварларны да шунда куймаска? Ойдәге вак-тоякләрне юып, чистартып шунда урнаштырдым. Еллар буе тузан жыеп яткан кисәv агачы, чvмеч һәм башкаларга да урын табылды. Керосин лампасы, жеп эрли торган жиһазларны... - дип сойләп китте әнгәмәдәшем.
Язма героебыз һәрбер экспонатка яна тормыш бирә, кадерләп саклый. Алар бит нәсел хәзинәсе; жылы хатирәләрне искә тошерә. Бу музейда галстук та бар, иске абажурлы лампочка да мәктәпкә бәйле вакыйгаларын янарта. Борынгы самоварда әби-бабайлары чәй кайнатып эчкән, керосинкада кетердәп тора торган таба бәрәнгесе, тәмле аш пешерә булганнар. Болар  барысы да әкияттәге шикелле генә хәтердә. Зур ләгәндә керугычта ышкый-ышкый кер юа булганнар. Болар барысы да әби-бабайларны сагындыра. Киләчәк буынга да менә дигән тарих.
Дербердеевлар ике кыз бала тәрбияләгәннәр, икесе дә югары белемлеләр. Аерым яшәсәләр дә, әти-әниләренә ярдәм итеп торалар. Шәһәрдән кайтучы оныклар да музей белән кызыксына. Алар очен ботенләй башка донья. Гульнара белән Альберт кебек әби-бабайлары булганда, нәсел тамырларын белеп vсәләр алар. Нәсел жепләре озелмәс. Буыннар vзгәрер, 10–20 елдан монда ботенләй башка экспонатлар урын алыр. Музейда әле урын житәрлек.

**Наилә НАСЫРОВА**